**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район с.Ташлы-Ковали, ул.Центральная, д.68

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Ташлы Кавал авылы, Үзэк ур., 68

Тел./факс: +7(84365) 70-4-16, e-mail: Tkv.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**19 октября 2020 ел** **№ 9**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Биектау муниципаль районының Ташлы Кавал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлегенең норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча, Биектау муниципального района Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының 2010 елның 4 октябрендәге 163 нче номерлы «Мөлкәткә салым турында» карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының 2011 елның 26 гыйнварендәге 21 нче номерлы «Ташлы-Кавал авыл җирлегенең Ревизия комиссиясе турындагы Нигезләмәне раслау турында»;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының 2011 елның 5 маендагы 29 нчы номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарын;

2011 елның 5 маендагы 30 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарында, сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының 2012 елның 12 декабрендәге 95 нче номерлы «Ташлы-Кавал авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын

биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Ташлы-Кавал авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында һәм шушы белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тапшыру турында» карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 мартындагы 153 нче номерлы «Әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене йогынтысыннан һәм тәмәке тарту нәтиҗәләреннән гражданнарның сәламәтлеген саклау турында Нигезләмәне раслау турында» карарын;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 мартындагы 155 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы-Кавал авыл җирлеге Советының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына тапшыру турында» карарын;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында, http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Хәйбуллин